ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03 10 2019 г. № 594

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 19 июнендәге 374 номерлы карары белән расланган Торак бинаны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак бинага күчерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентка үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 1491 номерлы карары нигезендә, Түбән Кама шәһәре прокуратурасының 2009 елның 30 июлендәге 02-08-01-19 номерлы протестын үтәү йөзеннән, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 19 июнендәге 374 номерлы карары (алга таба – регламент) белән расланган Торак бинаны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак бинага күчерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

регламентның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.5. пунктын түбәндәге эчтәлектәге 4-5 пунктчалар белән тулыландырырга:

«4) күпфатирлы йортта биналар милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәсе, анда торак бинаны торак булмаган бинага күчерүгә ризалык турында карар кабул ителгән булырга тиеш;

5) күчерелә торган бинага тоташкан барлык биналар милекчесенең торак бинаны торак булмаган бинага күчерүгә ризалыгы.».

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны басма матбугатта һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов